| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ТИМЯШЕВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТИМӘШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025елның 31 октябре №15

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү хакында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына таянып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьялары, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы белән, карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы, Тимәш авыл җирлеге, Тимәш авылы, Нефтьүткәргечләр урамы, 55 адресы буенча урнашкан - Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше (Ж1) «кибетләр» зонасындагы 576 кв. м мәйданлы, кадастр номеры 16:25:230103:232 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2025 елның 17 ноябренә 17 сәгать 30 минутта.

2. Җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

3. Гавами тыңлаулар үткәрү 2025елның 19 ноябреннән дә соңга калмыйча тәгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: https://leninogorsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Х.Х.Сөләйманова